ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

### 1 статья

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«федераль законнар нигезендә мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру;

иҗтимагый оешмалар катнашында мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төзү һәм аның турында нигезләмә раслау;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт, муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре хакында мәгълүмат урнаштыру;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфаты турында хезмәт күрсәтүләрне алучыларның фикерләрен белдерүнең техник мөмкинлеген тәэмин итү.».

### 2 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда түбәндәге эчтәлекле $16^1$, $16^2$ , $16^3$ һәм $16^4$ пунктлар өстәргә:

«$16^1$) федераль законнар нигезендә медицина оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру;

$16^2$) сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау буенча иҗтимагый берләшмәләр, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 76 статьясындагы 3 өлешенең таләпләренә туры килүче коммерциячел булмаган һөнәри медицина оешмалары (аларның вәкилләре) катнашында медицина оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төзү һәм аның турында нигезләмә раслау;

$16^3$) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт, муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта медицина оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре хакында мәгълүмат урнаштыру;

$16^4$) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында медицина оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфаты турында пациентларның фикерләрен белдерүнең техник мөмкинлеген тәэмин итү;»;

2) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары сәламәтлек саклау өлкәсендәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыра.».

**3 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешендә түбәндәге эчтәлекле $13^1$, $13^2$ , $13^3$ һәм $13^4$ пунктлар өстәргә:

«$13^1$) федераль законнар нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыра;

$13^2$) иҗтимагый оешмалар катнашында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төзи һәм аның турында нигезләмә раслый;

$13^3$) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт, муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем

бирү эшчәнлеге сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре хакында мәгълүмат урнаштыра;

13[4]) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфаты турында хезмәт күрсәтүләрне алучыларның фикерләрен белдерүнең техник мөмкинлеген тәэмин итә;»;

2) 19 статьяда:

а) 1 һәм 3 өлешләрдә «дәүләт аккредитациясе булган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Кабул итүнең контроль саннары гавами конкурс нәтиҗәләре буенча бүленә һәм, әгәр әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса, урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары нигезендә белем бирү өчен һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең, әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга билгеләнә. Кабул итүнең контроль саннары шулай ук, әгәр белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан Федераль законның 100 статьясында билгеләнгән таләпләр үтәлеп, урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программаларына дәүләт аккредитациясе элегрәк үткәрелмәгән булса, урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булмаган уку-укыту программалары нигезендә белем бирү өчен һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең, әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәре буенча билгеләнергә мөмкин.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 елның 16 марты
№ 14-ТРЗ